ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР № 3

Кече Ташкичү ав. 22.03. 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге
Советының 2023 елның 31 маендагы 10
санлы карары белән расланган Татарстан
Республикасы Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлегендә бюджет
процессы турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге

Советының 2023 елның 31 маендагы 10 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 23 маддәсендәге 7 өлешендәге 5 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«бюджет ассигнованиеләре бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга яңадан кертелгән һәм Россия Федерациясе дәүләт милке объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр биргән очракта».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы<br>
Ютазы муниципаль районы<br>
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы                    Р.К.Вәлиев